ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2025 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы
эшчәнлеге турында хисап хакында

2025 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турындагы хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турындагы хисапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшенең югары нәтиҗәлелеген билгеләп үтәргә, закон проекты эшчәнлеге һәм эксперт-аналитик чаралар үткәрү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген ассызыкларга.

3. Татарстан Республикасы Хисап палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмәләрне үз вакытында әзерләргә.

3.2. Татарстан Республикасы бюджетын һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетын формалаштыруга аудит үткәрергә.

3.3. Тикшереп тору чараларын үткәргәндә бюджет акчаларыннан, дәүләт мөлкәтеннән файдаланганда еш очрый торган хокук бозуларга һәм җитешсезлекләргә, коррупциячел куркынычларга игътибар итәргә һәм хокук бозуларны булдырмау максатларында тиешле мәгълүматны үз вакытында бюджет процессында катнашучыларга җиткерергә.

3.4. Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан тикшереп тору чаралары барышында ачыкланган системалы характердагы хокук бозуларның һәм җитешсезлекләрнең сәбәпләрен анализлауны дәвам итәргә.

3.5. Татарстан Республикасының бюджет кредитлары буенча бурыч йөкләмәләрен үз вакытында үтәүне, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән хисаплашуларны үз вакытында кире кайтаруны тикшереп торуны тәэмин итәргә.

3.6. Норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү һәм барыннан да бигрәк бюджет процессының сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән норматив хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү эшен дәвам итәргә.

3.7. Илкүләм проектларны, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны, шул исәптән аларның составы, план күрсәткечләре күләме һәм үтәлү нәтиҗәләре үзгәрүне исәпкә алып, мониторинглауны башкарырга.

3.8. Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен анализлау кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны финанслау күләмнәрен, бу программаларның күрсәткечләренә һәм чараларына төзәтмәләр кертелмәгәндә, дәлилләнмәгән үзгәртү фактларын ачыкларга.

3.9. Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен квартал саен мониторинглауны дәвам итәргә.

3.10. Тышкы муниципаль финанс контролен алга таба арттыру максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарына ярдәм күрсәтүне дәвам итәргә.

3.11. Илкүләм проектларны гамәлгә ашыруны мониторинглау кысаларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнары белән уртак тикшереп тору һәм эксперт-аналитик чаралар уздыру практикасын дәвам итәргә.

3.12. Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан тикшереп тору чаралары уздыру барышында ачыкланган җитешсезлекләр һәм хокук бозулар турында мәгълүматны квартал саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшыру эшен дәвам итәргә.

3.13. Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлегенең ачыклыгын, аның тарафыннан әзерләнә торган материаллардан һәркем файдалана алуны тәэмин итү эшен дәвам итәргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Хисап палатасы 2026 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мәгълүмат тапшырырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 8 июне
№ 629-VII ДС